КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 14 июль г.Казань № 571

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары вәкаләтле затларының электрон имзалары сертификатларын бирүне оештыру турында» 2007 ел, 28 апрель, 157 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 17 август, 712 нче һәм 2013 ел, 30 сентябрь, 701 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

2 пунктта «Татарстан Республикасының Мәгълүмат технологияләре үзәге» дәүләт унитар предприятиесенә» сүзләрен «Татарстан Республикасының Мәгълүмат технологияләре үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары вәкаләт биргән затларның санлы электрон култамгалары ачкычларына сертификатлар бирүне оештыру тәртибендә:

9 пунктның тугызынчы абзацын төшереп калдырырга;

10 пунктта «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасының Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары технологияләр өлкәсендәге «ИТ-парк» технопаркы» дәүләт автоном учреждениесен оештыру турында» 2010 ел, 22 март, 167 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 4 май, 322 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4. Гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсен үтәвен финанслар белән тәэмин итү, Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан раслана торган урта һөнәри белем бирү учреждениесенең финанс чыгымнары буенча тармак нормативларыннан һәм мөлкәтен карап тоту нормативларыннан һәм гамәлгә куючының билгеләнгән йөкләмәсеннән чыгып, дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы базасында пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы автобусларны мониторинглауның һәм диспетчерлаштыруның бердәм системасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2016 ел, 25 май, 352 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 16 апрель, 303 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктта «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә пассажирлар, шул исәптән балалар йөртүне гамәлгә ашыра торган автобусларны мониторинглау һәм диспетчерлаштыру бердәм системасы турындагы нигезләмәнең 2.4 пунктындагы өченче абзацында «Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «ГЛОНАСС яки ГЛОНАСС/GPS системасы навигация сигналлары кулланылып эшли торган, коммерция максатларында ташулар өчен файдаланыла торган М категорияле һәм куркыныч йөкләрне ташу өчен файдаланыла торган N категорияле транспорт чараларына куелырга тиеш булган навигация чараларына таләпләрне раслау турында» 2012 ел, 31 июль, 285 нче боерыгы нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Территорияләрендә кулланучылар фискаль документларны фискаль мәгълүматлар операторлары аша электрон формада салым органнарына мәҗбүри җибәрүне күздә тотмый торган режимда контроль-касса техникасыннан файдалана алган, элемтә челтәрләреннән ераклашкан Татарстан Республикасы торак пунктлары исемлеген раслау турында» 2017 ел, 30 май, 320 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Территорияләрендә кулланучылар фискаль документларны фискаль мәгълүматлар операторлары аша электрон формада салым органнарына һәм маркалауның мәгълүмат системалары операторына мәҗбүри җибәрүне күздә тотмый торган режимда контроль-касса техникасыннан файдалана алган, элемтә челтәрләреннән ераклашкан Татарстан Республикасы торак пунктлары исемлеген раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Территорияләрендә кулланучылар фискаль документларны фискаль мәгълүматлар операторлары аша электрон формада салым органнарына һәм маркалауның мәгълүмат системалары операторына мәҗбүри җибәрүне күздә тотмый торган режимда контроль-касса техникасыннан файдалана алган, элемтә челтәрләреннән ераклашкан Татарстан Республикасы торак пунктлары исемлеген (алга таба – Исемлек) расларга.»;

2 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

3 пунктта «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Территорияләрендә кулланучылар фискаль документларны фискаль мәгълүматлар операторлары аша электрон формада салым органнарына мәҗбүри җибәрүне күздә тотмый торган режимда контроль-касса техникасыннан файдалана алган, элемтә челтәрләреннән ераклашкан Татарстан Республикасы торак пунктлары исемлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Территорияләрендә кулланучылар фискаль документларны фискаль мәгълүматлар операторлары аша электрон формада салым органнарына һәм маркалауның мәгълүмат системалары операторына мәҗбүри җибәрүне күздә тотмый торган режимда контроль-касса техникасыннан файдалана алган, элемтә челтәрләреннән ераклашкан Татарстан Республикасы торак пунктлары исемлеге».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин